ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«СТАРОШУГУРОВСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Советская ул., дом 1, село Старое
Шугурово, Лениногорский район, 423282

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ИСКЕ ШӨГЕР
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Совет урамы, 1 нче йорт, Иске Шөгер
авылы, Лениногорск районы, 423282

Тел./факс: (8-85595) 3-45-42, Sshug.Len@tatar.ru, leninogorsk.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

27 апрель 2021ел №11

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Җирлек зиратында җирләү урыннарын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 6 декабрендәге 10 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законга нигезләнеп, КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Җирлек зиратында җирләү урыннарын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 6 декабрендәге 10 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

- Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Җирлек зиратында җирләү урыннарын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 6 декабрендәге 10 номерлы карарының 1 пункты үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Иске Шөгер авылы -җирле үзидарә бинасы, Совет урамы, 1 нче йорт, Совет урамы, 3 нче йорт, М. Җәлил урамы, 33 нче йорт, авыл. Яңа Шөгер авылы, Гагарин ур., 1/а, буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә һәм әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Иске Шөгер авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Л.М.Шиһапова